**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12. 11. 2015 № 830

г.Казань

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга бер тапкыр түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 27.07.2012 ел, № 604 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга бер тапкыр түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатыннан **боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга бер тапкыр түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 27.07.2012 ел, № 604 боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын расларга.”;

Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга бер тапкыр түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Боерык белән расланган административ регламентын кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итәргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының 12.11.2015 ел,
№ 830 боерыгына кушымта

**Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга бер тапкыр акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар:

1) 1917 елның 25 октябреннән (7 ноябреннән) Россия Федерациясе территориясендә ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге сәяси репрессияләргә дучар ителгән һәм “Сәяси репрессияләр корбаннарын аклау турында” 18.10.1991 ел, № 1761-1 Россия Федерациясе законына (алга таба – № 1761-1 РФ законы) туры китереп, хокук саклау органнары тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә акланган Россия Федерациясе гражданнары, элек СССРның республикалары булган дәүләтләр гражданнары, башка чит илләр гражданнары, гражданлыксыз затлар;

2) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче: элек СССРның республикалары булган дәүләтләр территориясендә ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге сәяси репрессияләргә дучар ителгән затлар, шулай ук әлеге репрессияләргә совет суд органнары яисә хәрби трибуналлар һәм СССРдан читтә эшләгән судтан тыш органнар карарлары буенча дучар ителгән, һәм шул дәүләтләрнең компетентлы органнары тарафыннан (әгәр аклау турындагы карар Россия Федерациясе законнарына каршы килмәсә һәм моңа охшаш компенсацияне алар әлеге дәүләтләрдән алмаган булу шарты белән) яисә элекке СССРның дәүләт органнары тарафыннан акланган затлар;

3) Россия Федерациясе территориясендә сәяси сәбәпләр буенча репрессияләнгән һәм № 1761-1 РФ законы кабул ителгәнгә кадәр билгеләнгән

тәртиптә акланган затлар;

4) бу пунктның 1, 2, 3 пунктчаларында күрсәтелгән затларның варислары, компенсация исәпләп язылган, ләкин акланган зат тарафыннан алынмаган очракта.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучылар, яки аларның законлы вәкилләре (закон белән билгеләнгән очракларда), яисә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар тора.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) йөзендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан күрсәтелә:

дәүләт хезмәте алучыларның яшәү урынында – Татарстан Республикасында даими яшәүче дәүләт хезмәте алучылар өчен;

дәүләт хезмәте алучыларның репрессия кулланылганга кадәр соңгы яшәү урынында – Россиядән читтә яшәүче дәүләт хезмәте алучылар өчен;

репрессия кулланылганга кадәр яшәгән урыннарын ачыклау мөмкин булмаган очракта, дәүләт хезмәте алучыларны Татарстан Республикасында репрессияләү кулланылган урында – Россия Федерациясеннән читтә яшәүче дәүләт хезмәте алучылар өчен.

1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адресы бу Регламентка белешмә-кушымтада күрсәтелгән.

Идарәнең (бүлекнең) эш графигы: Идарәнең (бүлекнең) эчке тәртип кагыйдәләре белән билгеләнүче эш сәгатьләрендә шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – Министрлык), Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында бу Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала;

2) "Интернет" челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның рәсми сайтынан: http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru);

3) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән

яки телефоннан);

4) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка (http://mtsz.tatarstan.ru) язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Идарә (бүлек) бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

“Сәяси репрессияләр корбаннарын аклау турында” 18.10.1991 ел, № 1761-1 Россия Федерациясе законына (алга таба – № 1761-1 РФ законы) (РСФСРның Халкы депутатлары съезды һәм РСФСР Югары Советы хәбәрләре, 1991, № 44, 1428 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президентының № 601 Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

СССР Югары Советы Президиумының “Дәүләтнеке һәм иҗтимагый оешмаларның, шулай ук үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә вазыйфаи затларның законсыз гамәлләре белән гражданинга китерелгән зыянны каплау турында” 18.05.1981 ел, № 4892-Х Указы (“СССР ЮС хәбәрләре, 1981, 741 ст.);

“Сәяси репрессияләр корбаннарын аклау турында” Россия Федерациясе законына туры китереп акланган затларга акчалата компенсация түләү һәм ташламалар бирү тәртибе турында “16.03.1992 ел, № 160 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган “Сәяси репрессияләр корбаннарын аклау турында” Россия Федерациясе законына туры китереп акланган затларга акчалата компенсация түләү тәртибе хакында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1992, 95 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 388 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү

һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 ТР МК карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү “тәрәзә”се.

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның формасы Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Ирегеннән мәхрүм итү, психиатрия дәвалау учреждениеләренә мәҗбүриләп дәвалауга урнаштыру рәвешендәге репрессияләргә дучар ителгән һәм соңыннан акланган затларга акчалата компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү | № 1761-1 РФ законының 15 ст. 1 абз. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге):<br>дәүләт хезмәте алучыларның яшәү урынында – Татарстан Республикасында даими яшәүче дәүләт хезмәте алучылар өчен;<br>дәүләт хезмәте алучыларның репрессия кулланылганга кадәр соңгы яшәү урынында – Россиядән читтә яшәүче дәүләт хезмәте алучылар өчен;<br>репрессия кулланылганга кадәр яшәгән урыннарын ачыклау мөмкин булмаган очракта, дәүләт хезмәте алучыларны Татарстан Республикасында репрессияләү кулланылган урында – Россия Федерациясеннән читтә яшәүче дәүләт хезмәте алучылар өчен. | Нигезләмәнең 4 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә кабул | |

| | | |
|---|---|---|
| оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | ителә (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта).<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорап алу зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү срогы гариза һәм документлар теркәлгән көннән алып ун эш көненә кадәр озайтыла. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1. Компенсация билгеләү турында гариза (почта адресын яки дәүләт хезмәте алучы тарафыннан кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын күрсәтеп) (бу Регламентка 1 нче кушымта). Дәүләт хезмәте алучыга акча күчерү өчен, опекун (химаяче) югарыда әйтелгән кредит оешмасында үзе ачкан номиналь счетның реквизитларын күрсәтә.<br>2. Акланганлык турындагы белешмә (яки аның дубликаты).<br>3. Иректән мәхрүм итү урыннарында булу вакыты турында эчке эшләр органнары тарафыннан бирелүче белешмә (яки аның дубликаты), яки психиатрия дәвалау учреждениеләрендә мәҗбүриләп дәвалауда булу вакыты турында шул учреждениеләр тарафыннан бирелүче белешмә (яки аның дубликаты).<br>Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (закон белән билгеләнгән очракларда), яисә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләрен тапшыра.<br>Гариза бирүче, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.<br>Россия Федерациясе территориясеннән читтә репрессияләнгән | Нигезләмәнең 4, 5, 7 п. |

һәм элек СССРның республикалары булган дәүләтләрнең компетентлы органнары тарафыннан акланып, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче затлар, үзләренең компенсациягә хокукларын № 1761-1 РФ законының 15 статьясына туры китереп раслау өчен, элек СССРның республикалары булган дәүләтләрдән моңа охшаш акчалата компенсацияне алмаганлыклары турында документ тапшыралар.

СССР Югары Советы Президиумының 1981 елның 18 маендагы “Дәүләтнеке һәм иҗтимагый оешмаларның, шулай ук үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә вазыйфаи затларның законсыз гамәлләре белән гражданинга китерелгән зыянны каплау турында” Указына тәңгәл рәвештә компенсация алган затлар түләнгән компенсациянең күләме хакында финанс органнары белешмәсен тапшыралар.

Гариза бирүче документларны һәм белешмәләрне тиешле оешмалардан ала, шул исәптән андый мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законына туры китереп расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, гаризага кушып бирелә торган документлар күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) Россия Федерациясе законына туры китереп расланган булырга тиеш.

Россия Федерациясеннән читтә яшәүче затлар Идарәгә (бүлеккә) гаризаларын (рус телендә тутырылган) һәм белешмәләрен (яки белешмәләрнең күчермәләрен) элемтә оешмалары аша җибәрергә мөмкин. Әлеге затларның имзалары раслатыла, ә белешмәләренең

| | |
|---|---|
| | күчермәләре, билгеләнгән тәртиптә, даими яшәү илендә урнашкан Россия Федерациясе дипломатик вәкиллекләре һәм консуллык учреждениеләре тарафыннан чит илдә яисә Россия Федерациясе территориясендә нотариус тарафыннан раслана. |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысасында Идарәнең (бүлекнең) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы аша җибәрелүче рәсми мөрәҗәгате буенча, Россия Федерациясе Генераль прокуратурасыннан № 1761-1 РФ законының 4 статьясында санап кителгән җинаятьләрне кылуда гаепләнелгән затларга карата элек СССРның республикалары булган дәүләтләр тарафыннан чыгарылган аклау хакындагы карарның Россия Федерациясе законнарына каршы килмәве турында йомгаклау нәтиҗәсе (алга таба – РФ Генераль прокуратурасының йомгаклау нәтиҗәсе) алына.<br>Гариза бирүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар кергән документларын бирергә хокуклы, шул исәптән, мөмкинлеге булганда, электрон рәвештә.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматлар кергән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан | Килештерү таләп ителми. |

| | |
|---|---|
| башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) электрон имза белән № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру.<br>3. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.<br>4. Бу Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып торалар:<br>ялган (дөрес булмаган) мәгълүматлар кергән документлар тапшыру;<br>РФ Генераль прокуратурасының бу Регламентның 2.6 пунктындагы 1 нче абзацта күрсәтелгән йомгаклау нәтиҗәсен бирүдән баш тартуы. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. |

| | | |
|---|---|---|
| өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының № 601 Указының 1 п. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен (шул исәптән электрон рәвештәге) теркәү срогы | Гариза һәм документлар кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырылган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән һәм:<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар: | № 880 ТР МК карары белән расланган |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен КФҮдә, ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>белгечләр тарафыннан Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы.<br>Гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә турыдан-туры – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә | Тәртипнең 2.4 п.;<br>РФ Президентының № 601 Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | кертеп, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны http://mtsz@tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) № 63-ФЗ һәм № 210-ФЗ Федераль законнар таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль закон;<br>№ 210-ФЗ Федераль закон |

## 3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) компенсация билгеләүгә гаризаны кушып бирелүче документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

4) компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны әзерләү һәм кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Идарәгә (бүлеккә) шәхсән үзе, телефоннан, почта аша, электрон почта аша, шул исәптән техник мөмкинлек булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгатьне гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, почта, электрон почта аша һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша гариза бирүчегә консультация үткәрә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан;

гариза бланкын бирә;

зарурлык булганда гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән

көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан искәртмәләр, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, консультация бирү (гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү) турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналына язып кую.

3.3. Компенсация билгеләүгә гаризаны кушып бирелүче документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту

3.3.1. Гариза бирүче, бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә, Идарәгә (бүлеккә) компенсация билгеләү турында гариза һәм аңа кушып, документларның күчермәләрен бирә.

Гариза һәм аңа кушып бирелүче документларның Россия Федерациясе законына туры китереп расланган күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) почта аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм № 63-ФЗ һәм № 210-ФЗ Федераль законнар таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) документлар (документлар күчермәләре) электрон документ рәвештә җибәрелергә мөмкин.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле сыйфатында эш итүче гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

барлык кирәкле документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның тиешенчә рәсмиләштерелгәнлеген, документларда аларда әйтелмәгән бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм бүтән төрле төзәтүләр булмауны) тикшерә.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуга нигезләр булу турында җиткерә һәм, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Гариза бирүченең таләбе буенча, баш тарту язмача рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче гариза һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә, Идарә (бүлек) белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә гариза һәм аңа кушып бирелгән документларын кабул итү датасы турында, бирелгән керү номеры турында белге белән расписка тапшыра, яки әлеге расписканы, электрон документ рәвешендә, гариза бирүче күрсәткән электрон почта адресына элемтә оешмалары аша Россия Федерациясеннән читтә яшәүче гариза бирүчегә, яисә,

“Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, гаризасын электрон документ рәвешендә биргән гариза бирүчегә җибәрә;

гариза бирүче күрсәткән почта адресына язмача җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы булдыру, расписка (документларны кабул итү көне турында хәбәрнамә) яки документларны кабул итүдән баш тарту турында гариза бирүчегә язмача хәбәр итү һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар; баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

3.4. Мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече, электрон рәвештә, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, РФ Генераль прокуратурасының йомгаклау нәтиҗәсен бирүен сорап, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: РФ Генераль прокуратурасының йомгаклау нәтиҗәсен бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.4.2. Идарә (бүлек) белгече, электрон рәвештә, йомгаклау нәтиҗәсен ала.

Процедура нәтиҗәсе: РФ Генераль прокуратурасының йомгаклау нәтиҗәсен алу.

3.5. Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны әзерләү һәм кабул итү

3.5.1. Бу регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән алынган йомгаклау нәтиҗәсе һәм гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

бу Регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән көннән башлап ике эш көне эчендә үтәлә. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорап алу зарурлыгы булганда – рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән моменттан ике көн эчендә, ләкин гариза теркәлгән көннән башлап җиде эш көненнән дә соңармыйча.

Процедуралар нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты.

3.5.2. Документларны карап тикшергәннән соң, Идарә (бүлек) җитәкчесе компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны имзалый һәм

Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты имза куюга җибәрелгән моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзаланган карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Идарә (бүлек) белгече:

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карарны, гариза бирүче күрсәткән ысул белән (хат рәвешендә, телефоннан, смс-хәбәр рәвешендә, электрон почта белән), гариза бирүчегә хәбәр итә;

билгеләү турында карар кабул ителгән очракта, гариза бирүченең “личное дело”сын рәсмиләштерә (барлык документларны бер папкага туплый).

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү, гариза бирүченең рәсмиләштерелгән “личное дело”сы (уңай карар кабул ителгән очракта).

